СОВЕТ
ТУКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ТУКАЙ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

пр. М. Джалиля, 46, г. Набережные Челны, 423800

М. Җәлил пр., 46, Яр Чаллы шәһәре, 423800

Телефон/факс (8552) 70-37-82, tukay@tatar.ru

6.12.2019 № 37/3
На № ________ от ______________

**Татарстан Республикасы бюджетыннан максатчан билгеләнештәге субсидияләр (башка бюджетара трансфертлар) финанс белән тәэмин итү чыганагы булып торган авыл җирлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү кагыйдәләре турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 142 статьясы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә муниципаль берәмлек Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Татарстан Республикасы бюджетыннан максатчан билгеләнештәге субсидияләр (башка бюджетара трансфертлар) финанс белән тәэмин итү чыганагы булып торган авыл җирлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү кагыйдәләрен расларга.

2. Әлеге кагыйдәләр рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә һәм 2020 елга бюджеттан башлап һәм 2021, 2022 еллар планы чорына Тукай муниципаль районы бюджетын төзегәндә һәм үтәгәндә кулланылырга тиеш.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http//pravo.tatarstan.ru), шулай ук Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (tukay.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны бюджет, салымнар, финанслар һәм икътисад буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы,
Совет Рәисе Ф.М. Камаев

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Советының 2019 елның 6.12. 37/3 номерлы карарына кушымта

**Татарстан Республикасы бюджетыннан максатчан билгеләнештәге субсидияләр (башка бюджетара трансфертлар) финанс белән тәэмин итү чыганагы булып торган авыл җирлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү кагыйдәләре**

1. Әлеге кагыйдәләр Тукай муниципаль районы авыл җирлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар (алга таба – башка бюджетара трансфертлар) бирү максатларын, шартларын билгели.

2. Башка бюджетара трансфертлар Тукай муниципаль районы авыл җирлекләренең чыгым йөкләмәләрен үтәүне финанс белән тәэмин итү максатында бирелә.

3. Башка бюджетара трансфертлар чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы бюджетына Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган субсидияләр (башка бюджетара трансфертлар) хисабына бирелә.

4. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты (алга таба – Башкарма комитет) әлеге кагыйдәләр нигезендә бирелә торган бюджет акчаларын баш бүлүче булып тора.

5. Башка бюджетара трансфертлар тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре һәм Башкарма комитетка билгеләнгән тәртиптә әлеге кагыйдәләрнең 2 пунктында каралган максатларга җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә.

6. Башка бюджетара трансфертларны бирү һәм файдалану шартлары булып тора:

- әлеге кагыйдәләрнең 10 пункты нигезендә башка бюджетара трансфертлар бирү турында килешү төзү;
- авыл җирлекләре җирле үзидарә органнары тарафыннан җирле бюджетларга Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 44 статьясында каралган бюджетара трансфертлар бирүнең төп шартларын үтәү.

7. Авыл җирлекләре бюджетларына бирелә торган башка бюджетара трансфертлар күләме Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының расланган норматив хокукый актлары белән билгеләнә.

8. Авыл җирлекләре бюджетлары арасында башка бюджетара трансфертларны бүлү Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының муниципаль хокукый акты белән раслана.

9. Башка бюджетара трансфертлар бирү Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты һәм авыл җирлеге Башкарма комитеты арасында төзелгән килешү

нигезендә Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан расланган формалар нигезендә гамәлгә ашырыла.

10. Килешүдә түбәндәгеләр карала:

- башка бюджетара трансфертлар күләме, аларның максатчан билгеләнеше;
- башка бюджетара трансфертларны күчерү тәртибе;
- башка бюджетара трансфертлардан файдалану турында хисап тапшыру сроклары һәм формалары;
- башка бюджетара трансфертларны алучының килешүдә каралган йөкләмәләр үтәлешен контрольдә тоту тәртибе;
- килешү шартларын бозган өчен якларның җаваплылыгы.

11. Авыл җирлекләре Башкарма комитетлары Тукай муниципаль районы Башкарма комитетына килешүдә каралган форма һәм тәртип буенча башка бюджетара трансфертлардан файдалану турында хисап тапшыралар.

12. Тукай муниципаль районы Башкарма комитетына тапшырыла торган мәгълүматларның дөреслеге өчен җаваплылык авыл җирлекләре Башкарма комитетларына йөкләнә.

13. Башка бюджетара трансфертлар район Башкарма комитеты тарафыннан Тукай муниципаль районы авыл җирлекләре бюджетларына Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсенең җирле бюджетлар үтәлешенә касса хезмәте күрсәтү өчен ачылган территориаль органнары счетларына килешүдә билгеләнгән срокларда күчерелә.

14. Башка бюджетара трансфертлар бирү шартларын бозган очракта, тиешле акчалар Россия Федерациясе бюджет законнарында билгеләнгән тәртиптә Тукай муниципаль районы бюджеты керемена күчерелергә тиеш.

15. Башка бюджетара трансфертлар бирү елыннан соң килүче елның 1 январена кадәр файдаланылмаган башка бюджетара трансфертлар калдыгы Россия Федерациясе Бюджет кодексында билгеләнгән таләпләр нигезендә Тукай муниципаль районы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш.

16. Башка бюджетара трансфертлар максатчан характерда була һәм, әлеге тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән максатлардан тыш, башка максатларда файдаланыла алмый.

17. Башка бюджетара трансфертларның максатчан кулланылышын контрольдә тоту Башкарма комитет һәм Тукай муниципаль районы финанс-бюджет палатасы тарафыннан законнар нигезендә гамәлгә ашырыла.